ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е К А Р А Р

10 сентябрь 2015 ел № 814

Нурлат муниципаль районы буенча 1999 елда туган гражданнарны хәрби исәпкә алуга әзерләү һәм үткәрү турында

"Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында "гы Федераль законның 9 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Нурлат шәһәре һәм Нурлат муниципаль районы буенча бүлеге (алга таба-ТР ВК бүлеге) башлыгына 2016 елның 1 гыйнварыннан 31 мартына кадәр район территориясендә даими һәм вакытлыча яшәүче, закон нигезендә билгеләнгән срокларда хәрби исәпкә куелмаган 1999 елгы һәм аннан өлкәнрәк хәрби хезмәткә чакырылу яшендәге ир-атларны исәпкә алуга беренчел куюны үткәрергә;

2. Милек формасына карамастан, авыл җирлекләре башлыкларына, предприятие, оешма, уку йортлары җитәкчеләренә:

1999 елда туган гражданнарның шәхси көн тәртибендә күрсәтелгән срокларда, барлык кирәкле документлар белән хәрби исәпкә беренчел кую өчен вакытында килүен тәэмин итәргә.

3. 1999 елда туган гражданнарны хәрби исәпкә алуга беренчел кую чорына ТР ХК бүлегенең чакырылыш пунктында медицина комиссиясе эшен тәэмин итәргә.

4. Хәрби исәпкә куелырга тиешле яшьләр арасында тәрбия эшен оештыру. Хәрби хезмәткә чакырылучылар белән әңгәмәләр үткәрү өчен Бөек Ватан сугышы ветераннарын, хезмәт һәм запастагы офицерларны җәлеп итәргә.

5. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге начальнигына 1999 елда туган егетләрнең урта мәктәпләргә физик әзерлек программасы нигезендә зачетлар тапшыруны оештырырга һәм аларны тулысынча колачлауга ирешергә.

6. Хәрби исәпкә алудан баш тарткан хәрби хезмәткә чакырылучыларны бергәләп эзләү өчен, ТР ХК бүлеге начальнигы карамагына беренчел хәрби исәпкә куюның бөтен чорына 2 милиция хезмәткәрен җибәрергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны чакырылыш комиссиясе рәисенә һәм ТР ХКның Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы буенча бүлеге начальнигына йөкләргә.

ТР Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Ә.К. Габдуллин